ГРАЖДАННАРЫ ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында**

КАРАР

23.11 2023 ел № 107

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Турай авыл җирлегенең Татар Әхтиялы авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. җыенында «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Турай авылы җирлегенең Татар Әхтиялы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә, ә махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә.

2. Алынган үзара салым акчаларын җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә

- Татар Әхтиялы авылында кар чистарту;
- ташландык йорт яны территорияләрендә үлән чабуга хезмәт хакы түләү һәм ягулык-майлау материаллары сатып алу;
- урам яктырту җайланмасы-3данә;
- триммер сатып алу;
-Урман урамы буенча вак таш җәю;
- вак таштан соң юлны тигезләү

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Турай авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Турай авыл җирлеге башлыгы Г.Б.Куляшова